Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

23 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 23 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылында узган 2019 елның 23 ноябрендә халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: чишмәләрне норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Бикәсаз авылы, Мәктәп урамы, 1А йорт торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гиниятуллина